**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 14 маендагы 1645 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 апрелендәге 1276 номерлы**
**«Ел саен уздырыла торган “Минем шәҗәрәм”**
**генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының**
**муниципаль этабын үткәрү турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законга туры китерү һәм ел саен уздырыла торган «Минем шәҗәрәм» генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабын оештыру тәртибен камилләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 20 апрелендәге 1276 номерлы «Ел саен уздырыла торган “Минем шәҗәрәм” генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының муниципаль этабын үткәрү турында»гы карарына, кушымтага 1, 2, 3 номерлы кушымталарны шул ук тәртиптә әлеге карарга 1, 2, 3 номерлы кушымталар нигезендә редакцияләп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 14 маендагы
1645 номерлы карарына
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм»
генеалогик тикшеренүләр республика конкурсының
муниципаль этабында катнашу өчен гариза**

| | |
|---|---|
| Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | |
| Катнашучының законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) | |
| Катнашучының туган көне | |
| Катнашучының яше | |
| Катнашучы белем ала торган мәгариф оешмасы | |
| Катнашучының тулы йорт адресы (индекс белән) | |
| Катнашучының элемтә өчен телефон номеры | |
| Катнашучының электрон почта адресы | |
| Конкурс эшенең атамасы | |
| Эш тапшырылган яшь төркеме | |

____________________/ ________________________________________________________

(Имза) (Катнашучының законлы вәкиленең инициаллары һәм фамилиясе)

20___ елның «___» ________________________

____________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 14 маендагы
1645 номерлы карарына
2 номерлы кушымта
(Форма)

**«Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабында катнашучы балигъ булмаган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә законлы вәкиленең ризалыгы**

Мин, ___________________________________________________________________,
(конкурста катнашучы балигъ булмаган затның законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

түбәндәге адрес буенча яшәүче: ________________________________________________,
(конкурста катнашучы балигъ булмаган затның законлы вәкиленең теркәлү урыны буенча адресы)

паспорт: сериясе ______________ №_______, _____ елның «___» ________________
____________________________________ тарафыннан бирелгән, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9, 11 статьялары таләпләре нигезендә Казан шәһәре, Кремль урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенә (алга таба – Оператор), «Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабын уздыруга бәйле рәвештә Оператор эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатыннан, түбәндәге белешмәләрне эшкәртүгә ризалык бирәм: минем шәхси мәгълүматларым: 1) фамилиям, исемем, атамның исеме; 2) шәхесне таныклаучы документ төре, сериясе, номеры, аны бирү датасы, биргән орган атамасы; 3) теркәлү урыны буенча адрес; 4) элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы; «Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабында катнашучы баламның (опекага алынган баланың), ________________________________________________________________________,
(конкурста катнашучы балигъ булмаган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

шәхси мәгълүматлары: 1) фамилиясе, исеме, атасының исеме; 2) туган көне, ае, елы, яше; 3) катнашучы белем ала торган мәгариф оешмасы атамасы; 4) конкурста катнашучының тулы йорт адресы (индекс белән); 5) конкурста катнашу нәтиҗәләре. Мин «Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабы турында нигезләмә белән танышуымны раслыйм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатлары: конкурс эшләрен формалаштыру һәм эшкәртү; тапшырылган конкурс материалларын карап тикшерү; конкурс йомгаклары буенча статистика һәм хисап алып бару; конкурс нәтиҗәләрен (катнашучыларның фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен, алган урыннарын, эшләренең исемнәрен дә кертеп) Операторның рәсми порталында бастыру; конкурста катнашучылар һәм аларның законлы вәкилләре белән хезмәттәшлеке тәэмин итү; конкурс эшен «Минем шәҗәрәм» республика конкурсын гамәлгә куючыга – Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетына, «Минем шәҗәрәм» республика конкурсын оештыручыга – «Татарстан Республикасы дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесенә тапшыру.

Миңа Операторның шәхси мәгълүматларым һәм баламның (опекага алынган баланың) мәгълүматлары белән шәхси мәгълүматларны җыю, туплау, системалаштыру, аныклау (яңарту, үзгәртү), саклау, файдалану, шәхси үзенчәлекләрне юк итү, алу, тыю, юкка чыгару

кебек  гамәлләр башкаруы турында хәбәр ителде һәм аларны башкарырга ризалыгымны бирәм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү ысуллары: автоматлаштырылган һәм автоматлаштырылмаган.

Оператор шәхси мәгълүматларны белешмәләрнең электрон базасына, исемлекләргә (реестрларга) һәм «Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабын уздыру белән бәйле хисап белешмәләре тапшыруны регламентлаштыра торган документларда каралган хисап бирү формаларына кертү юлы белән эшкәртергә хокуклы.

Операторның шәхси мәгълүматларны өченче затларга, алар тарафыннан мәгълүматларның конфиденциальлеген тәэмин итү шарты белән, әлеге ризалыкта күрсәтелгән максатларда гына (мәсәлән, дипломнарны бастыру өчен типографиягә) тапшырырга хокуклы булуы турында миңа хәбәр ителде.

Миңа шәхси мәгълүматларымны фәкать автоматлаштырылган юл белән эшкәртү нигезендә карарлар кабул итү тәртибе һәм мондый карарның мөмкин булган хокукый нәтиҗәләре аңлатылды, миңа мондый карарны кире кагу мөмкинлеге булу турында хәбәр ителде, шулай ук миңа үз хокукларымны һәм законлы мәнфәгатьләремне яклау тәртибе аңлатылды.

Мин, әлеге ризалыкны биргәндә, үз ихтыярым белән, үз мәнфәгатьләремне һәм конкурста катнашучы балигъ булмаган зат мәнфәгатьләрен яклап эш итүемне раслыйм.

Әлеге ризалык аны имзалаган вакыттан гамәлгә керә һәм эшкәртү максатларына ирешкәнче гамәлдә була.

Миңа шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны кире алу өчен Операторга шәхси гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәклеге хакында хәбәр ителде. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алу турында язма гаризам алынган очракта, Оператор аларны эшкәртүне туктатырга һәм гариза кергән көннән алып утыз эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә шәхси мәгълүматларны юк итәргә тиеш.

Шәхси мәгълүматларны яклау өлкәсендә хокукларым һәм бурычларым белән таныштым.

__________________/ ____________________________________________________________

(Имза) (Катнашучының законлы вәкиленең инициаллары һәм фамилиясе)

20___ елның «___» __________

_________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 14 маендагы
1645 номерлы карарына
3 номерлы кушымта
(Форма)

**«Минем шәҗәрәм» республика конкурсының муниципаль этабында катнашучының тарату өчен шәхси мәгълүматлар субъектының законлы вәкиле тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә законлы вәкилнең ризалыгы**

Мин, ________________________________________________________________,
(конкурста катнашучы балигъ булмаган затның законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
түбәндәге адрес буенча яшәүче: ___________________________________________,
(конкурста катнашучы балигъ булмаган затның законлы вәкиленең теркәлү урыны буенча адресы)
паспорт: сериясе ________________№________, _____елның «____» ______________ ________________________________________ тарафыннан бирелгән, телефон номеры ___________________, электрон почта адресы _____________________________________, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 10.1 статьясы таләпләре нигезендә Казан шәһәре, Кремль урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенә (алга таба – Оператор) баламның (опекага алынган баланың), ___________________________________________________________________,
(конкурста катнашучы балигъ булмаган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
шәхси мәгълүматларыннан чикләнмәгән даирәдәге затларга файдалану мөмкинлеге бирүгә ризалыгымны белдерәм:

| Шәхси мәгълүмат-ларның категориясе | Шәхси мәгълүматлар исемлеге | Таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Чикләнмәгән даирәдәге затларга таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк) | Шартлар һәм тыюлар | Өстәмә шартлар |
|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми шәхси мәгълүматлар | Фамилиясе | | | | |
| | Исеме | | | | |
| | Атасының исеме (булган очракта) | | | | |
| | Катнашучы белем ала торган мәгариф оешмасы атамасы | | | | |
| | Туу елы | | | | |
| | Туу датасы, ае | | | | |
| | Яше | | | | |

| **Шәхси мәгълүмат-ларның категориясе** | **Шәхси мәгълүматлар исемлеге** | **Таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк)** | **Чикләнмәгән даирәдәге затларга таратырга рөхсәт итәм (әйе/юк)** | **Шартлар һәм тыюлар** | **Өстәмә шартлар** |
|---|---|---|---|---|---|
| | Катнашучының тулы йорт адресы (индекс белән) | | | | |
| Биометрик шәхси мәгълүматлар | Бала сурәтләнгән фотосурәт | | | | |

«Минем шәҗәрәм» республика конкурсын уздыруга бәйле рәвештә Оператор эшчәнлеген гамәлгә ашыру, баламның (опекага алынган баланың) казанышларын күрсәтү максатыннан Операторның шәхси мәгълүматлар субъектының шәхси мәгълүматларыннан чикләнмәгән даирәдәге затларга файдалану мөмкинлеге бирелә һәм башка гамәлләр башкарыла торган мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр:

- Интернет челтәрендә Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталы: www.kzn.ru;
- социаль челтәрләрдәге сәхифә: https://vk.com/arhivkazan.

Мин эшкәртү өчен шартлар һәм тыюлар билгеләгән шәхси мәгълүматлар категорияләре һәм исемлеге, шулай ук билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге (теләк буенча тутырыла) ____________________________________________________________
____________________________________________________________.

Әлеге ризалык аны имзалаган вакыттан гамәлгә керә һәм аның гамәлдә булу вакыты чикләнмәгән.

Миңа шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымны кире алу өчен Операторга шәхси гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәклеге хакында хәбәр ителде. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алу турында язма гаризам алынган очракта, Оператор аларны эшкәртүне туктатырга һәм гаризам кергән көннән алып утыз эш көненнән дә артмаган вакыт эчендә шәхси мәгълүматларны юк итәргә тиеш.

__________________/ ____________________________________________________

(Имза) (Конкурста катнашучы балигъ булмаган затның законлы вәкиленең инициаллары һәм фамилиясе)

20_____ елның «_____» _________________

____________________